| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2024 Сарсак-Умга авылы № 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 23.01.2023 елның 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 23.01.2023 елның 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлекнең 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 32 пунктча өстәргә:

«32) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүм үзгәрешләр турында аңа мәгълүм булган мәгълүматлар турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр керми.»;

2) 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетаны;»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Т.С. Николаева